ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

**“ 29 ” сентябрь 2016 ел** **№ 1078**

**«Шәһәр төзелеше өлкәсендә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Арча район башкарма комитетының 2016 елның 14 июлендәге 793 номерлы карары белән расланган муниципаль берәмлек чикләрендә җирле әһәмияттәге юллар буйлап тулысынча яисә өлешчә уза торган маршрутлар буенча автомобиль йөкләрен, эре габаритлы йөкләр ташуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында Россия Федерациясе Салым кодексының 2000 елның 5 августындагы 117-ФЗ номерлы 333.33 статьясының 1 пунктындагы 111 пунктчасы, «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында» 2011 елның 01 февралендәге 87 номерлы башкарма комитет карары белән, Россия Федерациясе Салым кодексының 333.33 статьясының 1 пунктындагы 111 пунктчасы нигезендә Арча район башкарма комитеты карар бирә :

1. «Шәһәр төзелеше өлкәсендә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2016 елның 14 июлендәге 793 номерлы карары белән расланган муниципаль берәмлек чикләрендә тулысынча яисә өлешчә җирле әһәмияттәге юллар буйлап узучы маршрутлар буенча автомобиль йөкләрен, эре габаритлы йөкләр ташуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 2 бүлекнең 2.10 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.10. Муниципаль хезмәт күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яисә башка түләүне алу тәртибе, күләме һәм алу нигезләре | Дәүләт пошлинасы күләмнәре: автомобиль юлы буйлап йөртүне гамәлгә ашыручы транспорт чарасы хәрәкәтенә махсус рөхсәт биргән өчен (халыкара автомобиль ташуларны гамәлгә ашыручы транспорт чарасыннан тыш):<br>куркыныч йөкләр - 1300 сум;<br>авыр йөк һәм (яисә) эре габаритлы йөкләр - 1 600 сум | РФ НК 333.33 статьясының 1 пунктындагы 111 пунктчасы |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районы сайтында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (http:arsk.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерен торуны башкарма комитет җитәкчесе урынбасары О.Е.Спичкинга йөкләргә.

Җитәкче И.Ә.Галимуллин